ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Бурнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

07.11.2024 с. Большие Меми № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 9.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 2024 елның 22 ноябрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.
   1 этап: Олы Меми авылының Заречная, Исаевка урамнарында яшәүчеләр
   2 этап: Олы Меми авылының Яшьләр урамында яшәүчеләр
   3 этап: Олы Меми авылының Гаврилова Я.А., Үзәк урамнарында яшәүчеләр
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- Олы Меми торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Гражданнар җыеннарын уздырырга:

1 этап: Олы Меми авылы Заречная урамы 15нче йорт янында

2 этап: Олы Меми авылы, Яшьләр урамы 18нче йорт янында

3 этап: Олы Меми авылы, Гаврилов Я.А. урамы 45нче йорт янында

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина